ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 509-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.А. Ратникова, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 509-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2283-VI ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.А. Ратникова,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 7 һәм 8 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр үз көчләренә игълан ителгәннән соң керә.

8. Муниципаль хокукый актларны, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне игълан итү тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм алар белән гражданнарга танышу мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш, моңа фаш ителүе федераль закон белән чикләнгән белешмәләре булган муниципаль хокукый актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре керми.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $8^1 – 8^5$ өлешләр өстәргә:

«$8^1$. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне игълан итү дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгару;

2) муниципаль хокукый актны чикләнмәгән күләмдәге затлар күрерлек урыннарда урнаштыру (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр биналарында, кереп йөрү мөмкинлеген булган башка урыннарда);

3) муниципаль берәмлекнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру;

4) гражданнарны муниципаль хокукый акт белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итүнең муниципаль берәмлек уставында, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүдә, каралган башка ысулы.

$8^2$. Муниципаль хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең, тулы тексты тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугат басмасында беренче тапкыр басылуы, яисә тулы текстның челтәр басмада беренче тапкыр урнаштырылуы аның рәсми басылып чыгуы булып санала.

$8^3$. Муниципаль хокукый акт, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү, челтәр басмада рәсми бастырып чыгарылса, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлектә чикләнмәгән күләмдәге затлар, өстәмә техник чаралардан файдаланмыйча, куллана алырлык урыннарда (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр биналарында, кереп йөрү мөмкинлеген булган башка урыннарда) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташтырылган бер яисә берничә пункт булдыру тәэмин ителә.

$8^4$. Муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр, рәсми басылып чыккан вакытлы матбугат басмасының исеме һәм (яисә) челтәр басмасының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайттагы домен исемен һәм массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлүе турында белешмәләрне күрсәтеп, исеме муниципаль берәмлек уставында күрсәтелә.

$8^5$. Муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр халыкка игълан ителгән вакытлы матбугат басмаларының һәм (яисә) челтәр басмаларның, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайттагы домен исемен һәм массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлүе турында белешмәләрне күрсәтеп, исемлеге бөтен халык игътибарына муниципаль берәмлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән игълан ителә.»;

2) 15 статьяда:

а) 1 өлешнең 30 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең законлы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча

муниципаль программалар эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

б) 3 өлешнең 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең законлы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

3) 16 статьяның 1 өлешендәге 27 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең законлы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

4) 17 статьяның 1 өлешендә 34 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34) шәһәр округында балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең законлы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

5) 18 статьяның 7 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү, бүтән рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басманы гамәлгә кую;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

2023 елның 13 ноябрендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 517-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керде.

Әлеге Федераль закон белән барлык төрдәге муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре җирле үзидарә органнарының бу өлкәдә федераль законнарда («Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән вәкаләтләренә туры китерелгән.

Шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү тәртибе турындагы нигезләмәләре төгәлләштерелгән.

Аерым алганда, «халыкка игълан итү» һәм «рәсми бастырып чыгару» төшенчәләренең мәгънәләре аерылган. Алар нигезендә муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгару аны халыкка игълан итүнең бер ысулы булып тора. Шулай ук муниципаль хокукый актның тулы тексты вакытлы матбугат басмасында гына түгел, челтәр басмада беренче тапкыр басылып чыгу аның беренче тапкыр рәсми басылып чыгуы дип таныла.

Федераль законнардагы әлеге яңалыкларны закон проекты белән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законына кертү карала.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.